КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ПО ОХРАНЕ ОБЪЕКТОВ
КУЛЬТУРНОГО НАСЛЕДИЯ

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ МӘДӘНИ
МИРАС ОБЪЕКТЛАРЫН
САКЛАУ КОМИТЕТЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

18.03.2025 Казан шәһәре № 111-П

Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районында урнашкан «II Сакон каберлеге» ачыкланган мәдәни (археологик) мирас объектын ачыкланган мәдәни мирас объектлары исемлегенә кертү, территориясенең чикләрен һәм аннан файдалануның аерым режимын раслау турында

2002 нче елның 25 нче июнендә гамәлгә кергән 73-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкарьләр) турында»гы Федераль законы, 2005 нче елның 1 нче апрелендә гамәлгә кергән 60-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында»гы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 12 июлендәге 565 нче номерлы «Татарстан Республикасы мәдәни мирас объектларын саклау комитеты мәсьәләләре» карары белән боерам:

1. Әлеге боерыкка караган 1 нче кушымта нигезендә, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районында урнашкан "II Сакон каберлеге" археологик мирас объектын ачыкланган мәдәни мирас объектлары исемлегенә кертергә (бастырылып чыгарылырга тиеш түгел).

2. Расларга:

әлеге боерыкка караган 2 нче кушымта нигезендә, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районында урнашкан "II Сакон каберлеге" ачыкланган мәдәни (археологик) мирас объекты территориясе чикләрен (бастырылып чыгарылырга тиеш түгел).

әлеге боерыкка караган 3 нче кушымта нигезендә, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районында урнашкан "II Сакон каберлеге" ачыкланган мәдәни (археологик) мирас объекты территориясен куллануның махсус режимын

3. Мәдәни мирас объектларын исәпкә алу һәм шәһәр төзелеше эшчәнлеге бүлегенә ачыкланган мәдәни мирас объекты территориясе чикләре турында белешмәләрне Бердәм дәүләт күчемсез мөлкәт реестрына кертүне тәэмин итәргә.

4. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Рәис И. Н. Гущин

Татарстан Республикасы
Мәдәни мирас объектларын
саклау комитетының
2025 елның 18 нче мартындагы
111-П номерлы боерыгына караган
3 нче кушымта

Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районында урнашкан "II Сакон каберлеге" ачыкланган мәдәни (археологик) мирас объекты территориясен куллануның махсус режимы

Чикләрендә археологик мирас объекты урнашкан җир кишәрлекләреннән файдалануның махсус режимы 2002 нче елның 25 нче июнендәге 73-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкарьләр) турында" гы Федераль законда билгеләнгән тәртиптә (алга таба – 73-ФЗ номерлы Федераль закон), ачыкланган археологик мирас объектының сакланышын тәэмин итү, шулай ук гражданнарның аннан файдалана алуын тәэмин итү шарты белән 73-ФЗ номерлы Федераль законның 30 нчы статьясында күрсәтелгән җир, төзелеш, мелиорация, хуҗалык эшләрен башкаруны күз алдында тота.